| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2016 № 1421-п

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 01 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законның 26 маддәсенең 4 нче пунктында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 14 октябрендәге 2107/16 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 06 маендагы 566-п номерлы карары белән расланган «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 566-п номерлы карары белән расланган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Административ регламентның 2.5 пунктның 2 нче баганасындагы б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | б) эш урыныннан соңгы 12 ай өчен вазыйфасы һәм уртача хезмәт хакы күләме күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен-керемнәрне раслый торган башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгының күчермәләре). | |

2. Административ регламентның 2.6пунктның 2 нче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан кирәкле документлар:<br>- яшәү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яисә торак | |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырырга хокуклы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге. | урыныннан файдалану хокукын яки торак урынга милек хокукын раслаучы башка документ һәм яшәү урыныннан финанс шәхси счет күчермәсе;<br>- кеше тормышына һәм сәламәтлегенә каршы аңлы җинаять кылган өчен опекун булырга, хөкем ителергә теләк белдергән гражданинның булмавын раслаучы Эчке эшләр органнары белешмәсе;<br>- мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты;<br>- торак биналарының тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында белешмә (мөрәҗәгать итүче белән алдан килешенеп, опека һәм попечительлек органы белгече соравы буенча);<br>- эш урыныннан соңгы 12 айда уртача хезмәт хакы күләме һәм вазифасы күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен-керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен-пенсия таныклыгының күчермәләре). | |

11.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: **https://pravo.tatarstan.ru/.**

Җитәкче Р.М.Гасимов